**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге составына кергән Иске-Мунча торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**29.11.2020ел.** **№1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 30 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Иске-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1) *Иске-Мунча торак пунктында мөселман зираты территориясендә коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, капка кую, эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү нигезендә түләү);*
2) *Иске-Мунча торак пунктында зират өчен ләхеткә такталар сатып алу;*
3) *Кадрәк торак пунктында куакларны кырку, кисү, агачларны төпләү, гербицидлар белән эшкәртү (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү нигезендә түләү);*
4) *Иске-Мунча торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (тирәннән суырткыч насос, чишмә өчен полиэтилен торба сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).*

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 23 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 16 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 16 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1. 1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Иске-Мунча торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Иске-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга:

1) *Иске-Мунча торак пунктында мөселман зираты территориясендә коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, капка кую, эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү нигезендә түләү);*
2) *Иске-Мунча торак пунктында зират өчен ләхеткә такталар сатып алу;*
3) *Кадрәк торак пунктында куакларны кырку, кисү, агачларны төпләү, гербицидлар белән эшкәртү (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү нигезендә түләү);*
4) *Иске-Мунча торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (тирәннән суырткыч насос, чишмә өчен полиэтилен торба сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).*

3. Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында

(https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Кадрәк авыл җирлеге Башлыгы** ______________ **Х.Х.Нәбиуллин**
(имза) (тулысынча имза)